ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Иске Каразирек ав.

«04» декабрь 2023 ел № 37

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге Советы карарының үз көчен югалтуын тану турында

2006 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 02 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, норматив хокукый актларны Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразерик авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге Советының 2007 елның 03 июлендәге «Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау турында»гы 12 санлы карарын үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Э. М. Минниярова